ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 008 от « 03 » 02 2020 г.

Мамадыш муниципаль районының
террорчылыкка каршы комиссиясе турында

«Террорчылыкка каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ Федераль законның 4 статьясында каралган терроризмга каршы тору өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлегенең оештыру мәсьәләләре турында» 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы Указы, шулай ук Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия рәисенең 2018 елның 25 августындагы ПР-212 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Террорчылыкка каршы комиссиясенең 2018 елның 24 сентябрендәге ПР-239 номерлы утырышы беркетмәсен үтәү йөзеннән к а р а р б и р ә м :

1. Муниципаль район Башлыгының 2017 елның 1 ноябрендә кабул ителгән 112 нче номерлы, 2019 елның 26 июнендә кабул ителгән 084 номерлы карарларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссия составын (килешү буенча) расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясенә үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнар нигезендә турыдан-туры гамәлдә булган Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы көрәш комиссиясе рәисенең 2018 елның 25 августындагы ПР-212 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссиясенең типлаштырылган нигезләмәсенә һәм регламентына таянып эш итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль
район Башлыгы А.П.Иванов

000009

муниципаль район
Башлыгының “03”,
02 2020ел, 008 санлы
карарына 1 № кушымта

**Мамадыш муниципаль районында террорчылыкка каршы комиссиясе СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| 1. Иванов А.П. | Район башлыгы – муниципаль район Советы рәисе, комиссия рәисе |
| 2. Дәрҗеманов И.М. | Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| 3. Киндюшенко В.С. | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Яр Чаллы шәһәренең Алабуга шәһәрендәге дислокациясе белән вәкиле, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 4. Рылов О.Ю. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе, комиссия секретаре |
| | Комиссия әгъзалары: |
| 5. Әскәров А.Г. | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш районындагы бүлеге башлыгы |
| 6. Габдрахманов И.Н. | Муниципаль район Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| 7. Гарипов Р.М. | Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 8. Викентьев Е.И. | ТР буенча Россия Тикшерү комитетының Алабуга районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 9. Мөбәрәкшина Г.Р. | ТР буенча Федераль миграция хезмәтенең Мамадыш районы бүлеге башлыгы |
| 10. Мөхәммәтҗанов Р.К. | Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| 11. Руднев П.С. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Мамадыш муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр бүлеге башлыгы |
| 12. Сәмигуллин Р.Р. | Муниципаль район башлыгы урынбасары |
| 13. Смирнов А.П. | Муниципаль район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ башлыгы |
| 14. Синкевич А.В. | Татарстан Республикасының Мамадыш районы буенча ХК бүлеге башлыгы |
| 15. Смирнов П.А. | Муниципаль район Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче |
| 16. Спиридонов С.П. | Муниципаль район Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы |
| 17. Усачев Л.Б. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 18. Хаҗиев Д.Ф. | ДАСо «Мамадыш районы үзәк шифаханәсе” баш табибы |
| 19. Ханова С.Н. | «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы “Мамадыш- информ”җитәкчесе |
| 20. Хуҗаҗанов М.Р. | Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 21. Шәфигуллин Р.Н. | Россия Федерациясенең ТР Мамадыш районы буенча милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе” ФДКУ башлыгы |

Муниципаль район Советы
Аппараты җитәкчесе В. Н. Фәизов